Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга җирлеге Советы

**КАРАР № 16**

Югары Ырга авылы 2018 елның 15 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге "Физик затлар мөлкәтенә салым турында"гы 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының (икенче өлеш) 32 бүлегенә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Югары Ырга авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге "Физик затлар мөлкәтенә салым турында"гы 12 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 июнендәге 12 номерлы, 2015 елның 15 октябрендәге 17 номерлы, 2018 елның 30 октябрендәге 18 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлектәге 3.1 һәм 3.2 пунктлары белән тулыландырырга:

"3.1. 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да артыграк балалары булган гражданнарны физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә.

3.2.Салым ташламасы салым түләүче милкендә булган һәм аның тарафыннан кәсәбәчелек эшчәнлегендә файдаланылмаучы салым салына торган объектка карата салым түләүче түләргә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасын ачыклаганда салым ташламасы салым түләүченең сайлавы буенча һәрбер төрнең салым салына торган бер объектына карата салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә бирелә.

Салым ташламасы салым салына торган объектларның түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1)фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә;

2)торак йорт яки торак йортның бер өлеше;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 маддәсенең 1 пункты 14 пунктчасында күрсәтелгән бина яисә корылма;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының (?) маддәсенең 1 пункты 15 пунктчасында күрсәтелгән хуҗалык каралтысы яисә корылмасы;

5) гараж яки машина урыны.

Салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексының 406 маддәсенең 2 пункты 2 пунктчасында күрсәтелгән, салым салына торган андый объектларда урнашкан гараж һәм машина урыннарыннан гайре, салым салына торган объектларга карата бирелми.

Салым һәм җыемнар турындагы законнар белән билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар үзләренең сайлаулары буенча салым органына салым ташламасы бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүче салым ташламасына хокукынраслаучы документларын тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы бирелүче сайлап алынган салым салына торган объектлар турында белдерү хәбәре салым органына салым түләүче тарафыннан үзенең сайлавы буенча салым чоры булган елның 1 ноябренә (моннан башлап күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла) хәтле тапшырыла.

Салым органына сайлап алынган салым салына торган объектлар турында белдерү хәбәре тапшырган салым түләүче салым чоры булган елның 1 ноябреннән соң салым салына торган объектны (аңа карата күрсәтелгән салым чорында салым ташламасы бирелә) үзгәртеп аныкланган белдерү хәбәре тапшыра алмый.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче тарафыннан сайлап алынган салым салына торган объект турында белдерү хәбәре тапшырылмаганда салым ташламасы салымның максималь исәпләп чыгарылган суммасы белән һәрбер төрнең салым салына торган бер объектына бирелә.”.

2.Әлеге карар аның рәсми төстә бастырып чыгарылу көненнән үз көчен керә.

3.Карарның көче 2018 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салым исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Югары Ырга авылы, М.Җәлил урамы, 18 нче йорт; Яңа Ырга авылы, Мәктәп урамы, 48 нче йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Башкарма комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге башлыгы Р.Н.Баһаутдинов